ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары турында» Татарстан Республикасы Законының 9 һәм 10 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 111-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты А.А Чубаров тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары турында» Татарстан Республикасы Законының 9 һәм 10 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 111-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре
2025 елның 25 сентябре
№ 405-VII ДС

Проект
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы депутаты
А.А. Чубаров тарафыннан
кертелә

**«Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары турында»**
**Татарстан Республикасы Законының 9 һәм 10 статьяларына**
**үзгәрешләр кертү хакында**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗАКОНЫ

**1 статья**

«Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары турында» 1999 елның 17 ноябрендәге 2440 номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2000, № 1 (1); 2001, № 3; 2004, № 3 (IV өлеш); 2005, № 4 (I өлеш), № 7 – 8; 2006, № 11 (I өлеш); 2007, № 7 (I өлеш); 2011, № 8 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2012, № 3, № 6 (I өлеш); 2013, № 6 (II өлеш), № 11 (II өлеш); 2014, № 6 (II өлеш), № 7, № 11 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 54 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш), № 37 (I өлеш); 2021, № 49 (I өлеш), № 77 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 9 статьяда:
а) 2 пунктка түбәндәге эчтәлекле җөмләләр өстәргә: «Аларга Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте класслы чиннары бирелә. Җәмәгать судьясы аппараты хезмәткәрләре шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары булып тормаган вазыйфаларны да били ала.»;
б) 3 пунктта «штат расписаниесе» сүзләреннән соң «, Татарстан Республикасы Судьялар советы фикерен исәпкә алып,» сүзләрен өстәргә;

2) 10 статьяның 6 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«6. Җәмәгать судьяларының мәгълүмат ресурсларын берләштерелгән белешмәләр базаларына һәм белешмәләр банкларына кертү чаралары, аларны алып бару һәм алардан файдалануның бердәй технологияләрен уйлап табу, суд эшләрен башкаруны һәм эш башкаруны алып бару өчен кирәкле мәгълүмат системаларын булдыру һәм билгеләү, бердәй принциплар һәм гомуми кагыйдәләр нигезендә эшли торган мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләреннән файдалануга карата бердәй техник таләпләр кую Россия Федерациясе Югары Суды каршындагы Суд

департаменты һәм Татарстан Республикасында Суд департаменты идарәсе тарафыннан башкарыла.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары турында»**
**Татарстан Республикасы Законының**
**9 һәм 10 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында»**
**Татарстан Республикасы законы проектына**
**аңлатма**

«Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары турында» Татарстан Республикасы Законының 9 һәм 10 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты «Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары турында» 1999 елның 17 ноябрендәге 2440 номерлы Татарстан Республикасы Законын федераль законнарга туры китерү максатларында эшләнде.

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2025 елның 23 июлендәге 256-ФЗ номерлы Федераль закон белән җәмәгать судьясы аппаратының структурасын һәм штат расписаниесен билгеләү тәртибе төгәлләштерелә (хәзер ул Россия Федерациясе субъектының судьялар советы белән хезмәттәшлектә башкарылырга тиеш), шулай ук җәмәгать судьясы аппараты хезмәткәрләре шулай ук Россия Федерациясе субъекты дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары булып тормаган вазыйфаларны да били ала, дип билгеләнә.

Күрсәтелгән үзгәрешләр «Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары турында» Татарстан Республикасы Законы белән җайга салына торган нигезләмәләргә дә кагыла, шуңа бәйле рәвештә тиешле үзгәрешләрне кертү таләп ителә.

Закон проекты ике статьядан гыйбарәт.

Закон проектының 1 статьясында 9 һәм 10 статьяларга үзгәрешләр кертү тәкъдим ителә.

2 статьяда Татарстан Республикасы законының үз көченә керү тәртибе аның рәсми басылып чыккан көненнән дип билгеләнә.

**«Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары турында» Татарстан Республикасы Законының 9 һәм 10 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалткан дип танылырга, туктатылып торырга, үзгәрешләр кертелергә яки кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары**

**ИСЕМЛЕГЕ**

«Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары турында» Татарстан Республикасы Законының 9 һәм 10 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү җәмәгать судьясы аппаратының структурасын һәм штат расписаниесен билгеләгәндә Татарстан Республикасы Судьялар советы белән хезмәттәшлек итү тәртибе турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты актын кабул итүне таләп итә.

**«Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары турында» Татарстан Республикасы Законының 9 һәм 10 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында»Татарстан Республикасы законы проектына**
**ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

«Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары турында» Татарстан Республикасы Законының 9 һәм 10 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә финанс саралары бүлеп бирүне таләп итми.